**Рафис СӘЛИМҖАНОВ,**
*язучы, 1981-1985 елларда*
*«Ләйсән» әдәби берләшмәсе җитәкчесе*

# АЛДА УҢЫШЛАР КӨТӘ

...Ләйсән әдәби берләшмәсенә нигез салынуга шактый сулар аккан, шактый гомер үткән. Ләкин эшләнгән эшләр дә шактый. Шушы вакыт эчендә берләшмә Татарстан Язучылар союзына дистәдән артык язучы һәм шагыйрь үстереп бирде. Чулман буйларында тагын бер әдәби үзәк оешты. Бирегә бөтен республикага үзләренең шигырь-хикәяләре, очерклары, тәнкыйть мәкаләләре белән танылган яшь шагыйрьләр һәм язучылар тупланды: Хәниф Хөснуллин, Рәшит Бәшәр, Рәйсә Фәхразиева, Сәлимә Шәрипова, Рәсим Абдул, Фирдәвес Бәширова, Венера Хәбибрахманова, Әнвәр Шәрипов, Фирая Хәлиуллина, Шәрига Таһирова, Фаяз Дунай, Рәүф Гыйззәтуллин, Равил Лотфуллин исемнәре республика әдәбият сөючеләренә яхшы таныш.

РСФСР Язучыларының күчмә утырышында яшь прозаик Альберт Сафинның хикәяләре дә Мәскәү язучыларында шактый зур кызыксыну уятты. Аның да «Ак сиреньнәр» хикәясе «Литературная Россия» аша бөтенсоюз укучысына барып иреште. Альберт Сафин хикәяләренә әдәби нәфислек, тирәнлек хас. Аның «Идел» альманахында тиздән дөнья күрәчәк «Зәңгәр ут яктысында» исемле повесте да укучыларга матур бер бүләк булыр дип ышанасы килә.

Алда – яңа биеклекләр, яңа үрләр!

*Якты юл. – 1983. – 8 декабрь.*